РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 828** **13 май 2015 ел**

**Түбән Кама муниципаль районы
Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясына, Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең 30 статьясына, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставына таянып, **карар бирәм:**

1. Түбән Кама муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе тәкъдим иткән Түбән Кама муниципаль районының Кармалы авыл җирлегендә җир кишәрлекләренең бер өлешен күчерү өчен Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү графигын расларга:

а) Кармалы, Городище авылларында балалар мәйданчыкларын урнаштыру өчен, Ж-1 «Индивидуаль торак йортлар төзү зонасы»на;

б) Кармалы авылында ветеринария хастаханәсе һәм Городище авылында күпфункцияле үзәк төзү өчен, ОД-1 «Күпфункцияле иҗтимагый - эшлекле зона» зонасына ;

в) Кармалы авылында табиблык амбулаториясе төзү өчен, ОД-2 «Сәламәтлек саклау һәм социаль билгеләнештәге объектларны урнаштыру зонасы» зонасына;

г) Городище авылында кәрәзле база станциясен урнаштыру өчен, ИТ-1 «Инженерлык инфраструктурасы зонасы» зонасына

2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Түбән Кама муниципаль районы Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында» 2015 елның 19 мартындагы 673 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Нижнекамская правда», «Туган як» газеталарында бастырып чыгаруны һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Л.М. Тартминага йөкләргә.

Т.Х. Камалетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2015 елның 13 нче май
828 нче номерлы карары белән расланган
кушымта

**Түбән Кама муниципаль районы**
**Кармалы авыл җирлегендәге җир кишәрлекләренең бер өлешен күчерү өчен Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча эшләр башкару тәртибе һәм сроклары**

| **Чара** | **Үтәлү вакыты** | **Башкаручы** | **Искәрмә** |
|---|---|---|---|
| Тәкъдим ителгән документларны карау, комиссия бәяләмәсе | 05.05.2015 ел | Сиражетдинов Э.Р. Хисмәтуллин М.А. | Заказчы гаризасы, җиргә документлар, Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләреннән күчермә |
| Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итү | 14.05.2015 ел | Камалетдинов Т.Х. Сиражетдинов Э.Р. | «Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында» ТКМР Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе |
| Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын әзерләү турында карар кабул итү турында бастырып чыгару | 19.05.2015 ел | Массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге | «Нижнекамская правда», «Туган як» газеталарында, интернет челтәрләрендә күрсәтмәне бастыру |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын тәкъдим итү | 22.05.2015 ел | Камалетдинов Т.Х. Сиражетдинов Э.Р | ТКМР Башкарма комитеты җитәкчесенең ТКМР башлыгына Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында мөрәҗәгате |
| Түбән Кама муниципаль районы башлыгының Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында карары | 28.05.2015 ел | ТКМР башлыгы | ТКМР башлыгы гавами тыңлаулар билгеләү турында карар кабул итә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| ТКМР башлыгының Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында карарын бастыру | 02.06.2015 ел | ММЧ белән элемтә бүлеге | Карарны «Нижнекамская правда», «Туган як» газеталарында, интернет челтәрендә (5 көн дәвамында) |
| Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү | 02.08.2015 ел | Сиражетдинов Э.Р | 2 айдан 4 айга кадәр гавами тыңлаулар |
| Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү | 07.08.2015 ел | Сиражетдинов Э.Р | ТКМР башкарма комитеты Җитәкчесе өчен документлар әзерләү |
| Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын ТКМР Советына җибәрү турында карар кабул итү | 12.08.2015 ел | Камалетдинов Т.Х. Сиражетдинов Э.Р | ТКМР Советы депутат комиссиясенә карауга җибәр |
| Депутат комиссияләрендә карау, үзгәрешләр кертүне килештерү | 19.08.2015 ел кадәр | Долотказина Э.Р. | Комиссияләр карары |
| Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендәге үзгәрешләрне ТКМР Советы тарафыннан раслау | ТКМР Советының эш планы нигезендә | Долотказина Э.Р. | ТКМР Советы карары |

График «Кармалы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү тәртибе»нең 30 статьясы нигезендә төзелгән